МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.08.2013 № 498

г.Казань

“Татарстан Республикасында “Хезмәт ветераны” исемен бирүдә исәпкә алына торган аеруча хезмәтләр өчен ведомство билгеләре исемлеген раслау турында” 29.06.2012 ел, №481 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт органнарын һәм башка органнарны аеруча хезмәтләр өчен үзләренең ведомство билгеләре Татарстан Республикасында “Хезмәт ветераны” исемен бирүдә исәпкә алына торган органнар исемлегенә кертү тәртибе һәм шартлары турында”13.03.2012 ел, №210 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пункты нигезендә, боерык бирәм:

“Татарстан Республикасында “Хезмәт ветераны” исемен бирүдә исәпкә алына торган аеруча хезмәтләр өчен ведомство билгеләре исемлеген раслау турында” 29.06.2012 ел, №481 Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Дәүләт (ведомство) вазыйфаларын хәл итүдә катнашучы (катнашкан), хезмәттәге уңышлар һәм казанышлар өчен гамәлгә куелган аеруча хезмәтләр өчен үзләренең ведомство билгеләре Татарстан Республикасында “Хезмәт ветераны” исемен бирүдә исәпкә алына торган СССР, РСФСР, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм башка дәүләт органнары, СССР, РСФСР, Россия Федерациясе иҗтимагый берләшмәләре һәм оешмаларының үзәк органнары исемлегенә кертелгән дәүләт органнарының һәм оешмаларның аеруча хезмәтләр өчен ведомство билгеләре исемлегенә, исемлеккә искәрмәдә икенче-дүртенче абзацларны төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**Министр** **А.Р. Шәфигуллин**